**МИНИСТЕРСТВО ЭКОЛОГИИ И ПРИРОДНЫХ РЕСУРСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЭКОЛОГИЯ ҺӘМ ТАБИГАТЬ РЕСУРСЛАРЫ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** Казан ш. **БОЕРЫК**

14.05.2020 578-п

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының 2018 елның 2 июлендәге 642-п номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс үткәрү турындагы нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында

Норматив хокукый актларны федераль законнарга туры китерү максатында боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының «Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс үткәрү турындагы нигезләмә раслау хакында» 2018 елның 2 июлендәге 642-п номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс үткәрү турындагы нигезләмәнең 3.4 пунктының алтынчы абзацына үзгәреп кертеп, аны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«хезмәт кенәгәсе күчермәсе (хезмәт эшчәнлеге беренче тапкыр башкарыла торган очраклардан тыш), яисә гражданинның хезмәт эшчәнлеген раслый торган башка документлар һәм (яисә) хезмәт эшчәнлеге турында Россия Федерациясе Хезмәт кодексының $66^1$ статьясында билгеләнгән тәртиптә алынган белешмәләр;».

2. Хокукый тәэмин итү бүлегенә (М.М. Шәеховка) әлеге Боерыкның Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында дәүләт теркәвенә алынуын тәэмин итәргә.

3. Әлеге Боерык үтәлешен тикшереп тору буенча министрның беренче урынбасары Ф.Ф.Шакировны җаваплы итеп билгеләргә.

Министр А.В. Шадриков